ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.04.2025 ел Баулы шәһәре № 48

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 59 номерлы (2025 елның 4 апрелендәге 40 номерлы, 2024 елның 7 ноябрендәге 155 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) карары белән расланган белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУнең мәгълүмат-методик бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 7 статьясындагы 2 өлеше, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 131-ФЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге) «исеме» муниципаль берәмлек башкарма комитетының Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы 583/22 номерлы боерыгы белән расланган муниципаль берәмлек педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге) муниципаль берәмлек башкарма комитеты составындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2025 елның 7 апрелендәге под-608/25 номерлы боерыгы белән үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы под-583/22

номерлы боерыгы белән расланган,Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы  Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

К А Р А Р  Б И Р Ә :

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 59 номерлы карары белән расланган белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең мәгълүмат-методик бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 7 ноябрендәге 155 номерлы, 2025 елның 4 апрелендәге 40 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

II «Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне билгеләү» бүлектә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ структурасындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификацион дәрәҗә | Вазыйфа атамасы | Айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестация уңышлы үтеп кергән затка “бакалавр”, “магистр” яки “дипломлы белгеч” квалификациясе бирелүне раслаган югары һөнәри белем бирү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификацион дәрәҗә | Методист | - | - | 22271,0 |
| Дүртенче квалификацион дәрәҗә | Өлкән методист | - | - | 22276,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификацион төркеме | | | | |
| Беренче квалификацион дәрәҗә | Структур бүлек мөдире (начальнигы) урынбасары: муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация | - | - | 22362,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек | | | |
| | Структур бүлек мөдире (начальнигы): муниципаль берәмлекләрнең мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек | | | 22446,0 ». |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров